**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әгерҗе авылы №138-99 «07» июнь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2022 елның 16 декабрендәге 78-45 номерлы «Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2022 елның 16 декабрендәге 78-45 номерлы «Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«- җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча, Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән вакыт узганнан соң, 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Маяк»район газетасында мәгълүмати хәбәрне бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Н.Хәсәнов